ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

---

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

6 июнь 2024 ел №3-48

Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча
бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законына, «Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр билгеләү максатыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тану өчен түбәндәге өстәмә нигезләрне билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәбендә бурычлар булу;

3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р. Р. Камартдинов